КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 01 февраль г.Казань № 82

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 995 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 995 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча өстәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт - Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең норматив чыгымнарына карата 1,0018 тигез булган төзәтү коэффициенты билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган 2023 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарында:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы учреждениеләре» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «$12^1$. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт - Ак Барс» | дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү) | 65 469 754,0». |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | | |

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин